
Гыйләҗев, Х.  Күңеле моңнан хасил / Х. Гыйләҗев // Мәдәни җомга. – 2024. – №25 (28 июнь). – Б. 15.

# Күңеле моңнан хасил!

***Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, үзешчән композитор Рубис Зариповка 85 яшь***



Рубис Зариповны Чаллы төбәгендә белмәгән кеше сирәк. Ул язган китаплар, ул иҗат иткән җыр-моңнар бөтен Татарстанга тарала. Лаеш районындагы «Санта» шифаханәсендә мәдәният хезмәткәре Илсөя Туктарова үткәргән чараларның берсендә ял итүчеләрне Рубис Зарипов иҗаты, белән таныштырдылар. Аның турында атказанган мәдәният хезмәткәре, профессиональ җырчы Разыя Гайнуллина сөйләгән иде, экран аша Чаллының «Энергетик» сараенда узган җыр бәйрәмедә күрсәтелде. Рубис ага һәр җирдә көтеп алынган кунак булды: Чаллының «Радуга», Менделеев районындагы «Ижминводы» шифаханәләре, «Яр Чаллы» клиника-санаторие, мәктәпләр, китапханәләр, ветераннар өчен пансионатлардагы очрашулардан, кайтып керми иде ул. Тукай районында туган авылы Теләнче Тамак, Яңа Бүләк, Таулар, Казаклар авыллары, Саба районының Сатыш авылы, Арча районында Кырлай авылы - болар Рубис ага кат-кат йөреп чыккан җирләр исемлегенең бер өлеше генә. Түбән Каманың Г. Тукай паркы, Чаллының Җиңү паркы һәм ипподромында, телевидение-радио каналларында да аның чыгышлары хәйран калдыра. Бер елга йөзгә якын очрашу, йөзләп чыгыш!

Соңгы елларда сәламәтлеге какшау үзен сиздерә, очрашуларга бик йөри алмый. Ике кызы, оныклары гел кайгыртып торалар үзен, җәмәгате генә иртәрәк китте шул... Җае чыкканда мин өлкән дустым Рубис аганың хәлләрен белешәм, акыллы киңәшләрен тыңлыйм, рухи байлык җыям. Аның халык арасында шулкадәр мәхәббәт казануы, популяр, үз кеше булуының сере нидә икән, дип уйланам, үземчә нәтиҗә чыгарам.

Рубис ага эчкерсез-ихлас, хәйләкәрләрне җене сөйми, аннан соң Академиядә югары хәрби-юридик белем алып, 30 елга якын хезмәт-төзәтү учреждениеләрендә хезмәт итә, анда тормышның башкалар күрмәгән-аңламаган якларын ача, тәҗрибә туплый. «СССРның ЭЭМ отличнигы» исеменә лаек була. Югары хәрби белем алгач, үз һөнәре буенча генерал дәрәҗәсенә күтәрелерлек вазифалар тәкъдим иткәннәр аңа, ул ризалашмаган, кайчан да булса үз милләтенә якынаячагына, аңа хезмәт итәчәгенә ышанып яшәгән. Илһам Шакиров белән бер мәктәптә укы да. анын белән яшүсмер чакта авыл клубларында бергә җырлап йөр дә. шуларны оныт, имеш. 1986 елда отставкага чыгып, туган ягына әйләнеп кайткач та иҗат эшенә чума. Музыкага һәм әдәбиятка тартылуы бу өлкәдә тумыштан килгән таланты аркасында. Ул 30 дан артык китап авторы, 400 ләп җырга көй язучы да. Үзе тальянда уйнап, югары дәрәҗәдә җырлап та күрсәтә.

Әле балачакта бер тапкыр булса да Рәшит Ваһаповның үзен күреп кала ул, күңеле җыр белән сихерләнү шул чактан бирле яши. 1951 елда туган авылына Рәшит Ваһапов килә. Әтисенең бертуган энесе, үзенә тальян гармун да алып биргән хисапчы булып эшләүче Гыйльмулла абыйсы озын шинель-пальто итәгенә яшереп алып керә аны концертка. Еллар үткәч, Россиянең халык артисты Илһам Шакиров та, авылдашы, Казан университеты профессоры Флера Сафиуллина һ.б. әйтә: музыкаль белем алырга кирәк сиңа, диләр. Юллар башкачарак булып чыга шул..

Рубис абый 2000 елның 2 сентябрендә күп мәшәкатьләр үтеп, төрле инстанцияләрдә булып, Теләнче Тамак авылының бер урамына үзе исән чакта Илһам Шакиров исемен бирдерүгә ирешә. Авыл халкы катнашында олы тантаналы чара үткәрелә. «Илһам Шакиров урамы» дигән тактаны урам чатына, ә ул яшәгән йортка - «Бу йортта 1951-1954 елларда халкыбызның бөек җырчысы Илһам Гыйльметдин улы Шакиров яшәде» дигән мемориаль такта беркетәләр. Мәрмәр ташларның икесенә дә үзе чокып яза.

Рубис ага Зарипов 2019 елның 21 гыйнварда Г. Кариев исемендәге Яшь тамашачылар театрында узган «Алтын тавышка - «Алтын Акчарлак» бәйгесенең Гран-приена лаек булган иде. Ул вакытта җиңүчегә «Алтын акчарлак» сынын бүләк иттеләр. Р. Зарипов Татарстанның халык артисты Габделфәт Сафинның Казан концертында җырлау бәхетенә ирешә, халык аны мөкиббән китеп тыңлады.

Моннан дистә ел элек булган Сабан туйларына халкыбызның милли гореф-гадәтләрен үз күзләре белән күреп кайтырга дип АКШтан татар теле һәм тарихын өйрәнүче ике галим - Паул Куйвинен һәм Эрик Ожарне Татарстанга килә. Аларны .хакимият вәкилләре Тукай районының Теләнче Тамак авылында җәй үткәрүче милләт зыялысы Рубис ага Зарипов белән дә таныштыра. Америка кунаклары саф татарча сөйләшә. Аларны иң гаҗәпләндергәне шул -1949 елгы агач йортта гади генә яшәп һәм иҗат итеп ятучы, милләтнең бөтен уңай сыйфатларын үзенә сеңдергән, тере энциклопедиягә тиң кешеләргә карата дәүләтнең битарафлыгы. Рубис ага янында үткән бер көн чит ил галимнәренә фәнни хезмәт язарга җитә. Ә бездәге уку программалары буенча мондый әйберләр хәтта студентларга да кирәксез.

Рубис Таҗи улы Зариповның да киләчәк буыннар өчен кирәге чыгар дип, олыгайган көнендә компьютер алдына утырып, күз нурларын түгеп, патриотик темага язган 4-5 китабы басылмый ята. Басылганнарынын күпчелеген үз акчасына чыгарган. Татарстан Дәүләт Советы депутаты булып торган чорда шәһәрләшем Рафаил Нуретдинов бик ярдәм итте. андый депутатлар калмады шул хәзер, дип көрсенеп куя ветеран.

Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ, **хезмәт ветераны.**